ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» июнь 2020 ел № 191

**2020 елга 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнар өчен вакытлыча эшләр оештыру турында**

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «2020 елга халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүнең территориаль программаларын эшләү һәм килештерү турында» Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 04 февралендәге 64 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре җитәкчеләренә түбәндәгеләрне оештырырга тәкъдим итәргә:

- 2020 елда «Менделеевск районы буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» филиалы белән берлектә район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре эшчәнлеге барышында булдырыла торган эш урыннары санын исәпләп, балигъ булмаган гражданнарны каникул һәм укудан ирекле вакытта эшкә урнаштыру өчен вакытлыча эшләр оештырырга (1 нче кушымта);
- вакытлыча эшкә җәлеп ителә торган балигъ булмаган гражданнарның хезмәт хакын федераль законнар белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләме (бердәм социаль салымны да кертеп) күләмендә түләүне оештырырга.

2. 2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында теркәлгән 200 балигъ булмаган гражданны эшкә урнаштыруга җәлеп итеп, вакытлыча эшләрнең төп төрләре исемлеген расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны үтәгәндә учреждениеләр, оешмалар, район предприятиеләре җитәкчеләренә халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте чаралары һәм эш бирүчеләр хисабына халыкны эш белән тәэмин итүне оештыру турындагы Нигезләмәгә халыкның мәшгульлегенә булышлык итү һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын финанслау тәртибе турындагы нигезләмәдә каралган суммалар чикләрендә таянырга тәкъдим итәргә (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2006 елның 4 сентябрендәге 624 номерлы «Халыкның мәшгульлегенә булышлык итү һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын финанслау тәртибе турындагы

нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» боерыгы)

4. ДКУ «Менделеевск районы буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» филиалына эш бирүче оешмалар белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән балигъ булмаган гражданнарны, гаризалар нигезендә, эш белән тәэмин итүне оештыру турында килешүләр төзергә тәкъдим итәргә.

5. Предприятие, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- эш вакыты нормалары чикләрендә балигъ булмаган гражданнар өчен вакытлыча мәшгульлек оештырырга;

- гражданнар тарафыннан эшкә җибәрелә торган хезмәт килешүләре төзүне һәм хезмәтне саклау буенча норматив актларның һәм җитештерүдә куркынычсызлык техникасының үтәлешен тәэмин итәргә.

6. ДКУ «Менделеевск районы буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» филиалы белән берлектә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә оештырыла торган вакытлы эшләр күләмнәрен, эшсез халык санын һәм составын исәпкә алып, территориянең социаль инфраструктурасын үстерү зарурлыгыннан чыгып, тәгаен билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларына кураторлык итүче юнәлешләр буенча мәшгуль булмаган халыкны вакытлы эшләрдә катнашу тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат белән тәэмин итү эшен оештырырга.

8. МКУ «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе»нә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, ДКУ «Менделеевск районы ЦЗН» филиалына вакытлы эшләр үткәрүне оештыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

9. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **А.Р. Вәлиев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
23 июнь 2020 ел №191
карарына 1нче кушымта

**2020 елда «Менделеевск районы буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» филиалы белән берлектә район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре эшчәнлеге барышында булдырыла торган эш урыннары санын исәпләп, балигъ булмаган гражданнарны каникул һәм укудан ирекле вакытта эшкә урнаштыру өчен вакытлыча эшләр**

| Предприятие, оешмалар, учреждениеләр | Булдырыла торган эш урыннары саны |
| --- | --- |
| Әгерҗе район кулланучылар җәмгыяте | 1 |
| ООО «Агро-Престиж» | 1 |
| ООО «Навруз» | 2 |
| ООО «Агрофирма-Агрыз» | 1 |
| 2 НЧЕ САНЛЫ МӘКТӘП | 1 |
| 4 НЧЕ САНЛЫ МӘКТӘП | 1 |
| «Мәгариф идарәсе МКУ» | 193 |
| БАРЛЫГЫ | 200 |

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
23 июнь 2020 ел №191
карарына 2нче кушымта

**2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында теркәлгән 200 балигъ булмаган гражданны эшкә урнаштыруга җәлеп итеп, вакытлыча эшләрнең төп төрләре исемлеге**

1. Авыл хуҗалыгы эшләре: авыл хуҗалыгы культураларын карау һәм уңыш җыю, шәһәр һәм квартал эчендәге территорияләрне җыештыру.
2. Җитештерү участокларында (зарарлы хезмәт шартларыннан башка) җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыру.
3. Шәһәр урманнарын көнкүреш чүп-чарыннан, ауган агачлардан (коры-сары кисүдән башка) җыештыру.
4. Шәһәр һәм район территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү.
5. Белем бирү учреждениеләре, спорт мәйданчыклары, ял итү урыннарын төзекләндерү (чәчәкләр, куаклар утырту, су сибү, утау).
6. Куаклар кисү (биеклеккә күтәрелмичә).